Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Каргалы авыл җирлеге
Советы

КАРАР

19.04.2024 ел № 46/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында «05.06.2019 ел 74/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында «Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында« 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чистай шәһәр прокурорының 15.03.2024 ел,02-08-02-2024  номерлы протестын карап чыгып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының 05.06.2019 ел 74/3номерлы  карары белән расланган» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 8 статьяның 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчасы белән тулыландырырга:
«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).»;
1.2. 11 статьяның 1 пунктының 8 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерергә:
"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;
1.3. 13 статьяның 3 пунктының 2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерергә:

"2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;";
1.4. 20 нче маддәнең 2 нче пунктында:
11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;
түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункт белән тулыландырырга:
«11.1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;».
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Каргалы авыл җирлеге башлыгы М.А. Загидуллин